**СОВЕТ АЛЬДЕРМЫШСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ВЫСОКОГОРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БИЕКТАУ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ӘЛДЕРМЕШ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕСОВЕТЫ**

422711, Республика Татарстан, Высокогорский район,
с. Альдермыш, ул. Хабибуллина, 2

422711, Татарстан Республикасы, Биектау районы,
Әлдермеш авылы, Хабибуллин урамы, 2

тел./факс 8(84365) 79-4-03, e-mail: Alder.Vsg@tatar.ru

---

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**
**20 март 2025 ел** **№125**

**Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының Әлдермеш авыл җирлеге Советының «Җир салымы турында» 12.11.2019 № 1769 карарына үзгәрешләр кертү хакында**

Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Прокуратурасының 04.02.08-01 номерлы протесты нигезендә, Россия Федерациясе Салым кодексы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының Әлдермеш авыл җирлеге Советы нигезендә КАРАР ИТТЕ:

1. Биектау муниципаль районы Әлдермеш авыл җирлеге Советының «Җир салымы турында» 2019 елның 12 ноябрендәге 169 номерлы карарына (Советның 19.05.2020 № 189, 18.07.2022 №54, 29.11.2022 №66, 29.11.2022 №67, 28.12.2023 №83 карарлары редакциясендә) түбәндәгеләрне үзгәрешләр кертергә:

1.1.2 пунктның 1 пунктчасындагы 3 абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«-торак фонды һәм (яисә) торак-коммуналь комплексының инженерлык инфраструктурасы объектлары биләгән (торак фондына һәм (яисә) торак-коммуналь комплексының инженерлык инфраструктурасы объектларына карамаган күчемсез мөлкәт объектына туры килә торган җир кишәрлегенең өлешеннән тыш) яисә торак төзелеше өчен сатып алынган (бирелгән), әлеге абзацта күрсәтелгән җир кишәрлекләреннән тыш, индивидуаль торак төзелеше өчен сатып алынган, эшкуарлык эшчәнлегендә файдаланыла торган җир кишәрлекләре һәм җир кишәрлекләре, аларның һәрберсенең кадастр бәясе 300 миллион сумнан артып китә;»

2. Биектау муниципаль районының Интернет челтәрендәге рәсми сайтында түбәндәге веб-адрес буенча әлеге карарны халыкка җиткерергә: http://vysokaya-gora.tatarstan.ru/ һәм Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында: http://pravo.tatarstan.ru.

3. Әлеге карар Россия Федерациясе Салым кодексының 5 статьясы нигезендә законлы көченә керә.

4.Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

Совет Рәисе,
Авыл җирлеге башлыгы Н.А.Усманов